# 1 Май мәйданы – тарих шаһиты

## КАЗАН КРЕМЛЕНЕҢ СПАСС МАНАРАСЫ КАРШЫНДАГЫ МӘЙДАН – ШӘҺӘРНЕҢ ҮЗӘК ҺӘМ ТАРИХИ УРЫННАРЫНЫҢ БЕРСЕ

**Совет чорында ул 1 Май мәйданы дип атап йөртелә башлады. Октябрь революциясеннән соңгы беренче майда аңа шул исем бирелгән. Ул көнне бирегә шәһәрнең төрле почмакларыннан кызыл байраклар күтәреп, колонналар агыла.**


Дамир БӘДРИЕВ фотосы

Бу мәйданның берничә тарихи атамасы бар: Спасс мәйданы, Иванов мәйданы (биредә Ионно-Предченский монастыре урнашкан булган), Александров мәйданы (XIX гасырның ахырында биредә патша Александр II һәйкәле барлыкка килә). 1552 елның 2 октябрендә Казанны соңгы штурмлау көнендә биредә Христос Спаситель сурәтен чагылдыручы патша байрагы җилферди. Шуннан соң тиз арада бирегә агач чиркәү төзелә. Мәйдан Спасс мәйданы дип йөртелә башлый.

Революциядән соң «азат итүче патша» һәйкәле сүтелә. Манарадан ике башлы бөркет сыны һәм коткаручы Спасс образы алып ташлана, часовня ябыла. 1930 елда Кремльгә керү юлы турайтылгач, часовня бөтенләй сүтелә.

1960 елда Казанның 1 Май мәйданында татар халкының бөек шагыйре Муса Җәлилгә һәйкәл төзү турында карар кабул ителә. Танылган совет скульпторы Владимир Цигаль шагыйрьне тимер чыбыкка уралган, шулай да җирдә ирекле адым ясаучы буларак сурәтли. Муса Җәлилгә һәйкәл мәйданга 1966 елның 4 ноябрендә куела.

1 Май мәйданының көнчыгыш тарафында республиканың Милли музее урнашкан. Бу урында әле XVIII гасырда ук төзелгән бинаны «гостиный двор» дип йөрткәннәр. Шушы чордан бирле бина күп тапкырлар үзгәртелә. 1800-1815 елларда Пугачев бунты вакытында бина бөтенләй диярлек җимерелә. Янгыннар һәм җимерүләр кичергән бина элеккеге сурәтендә кабаттан торгызыла.

Гостиный двор 1891-1895 елларда музей булып формалаша. Бинаның төньяк-көнбатыш өлеше Казан шәһәр фәнни-сәнәгать музеена тапшырыла. Гостиный двор бинасы архитектор И.Н.Колмаков проекты буенча музей эчтәлегенә җайлаштырыла. Фондның төп өлешен Казан археологы, тарихчы А.Ф.Лихачевның экспозициясе били. Музей башлангычында туган якны өйрәнү экспедицияләре оештырыла. 1920 елларда биредә Россия музейларының бердәнбер журналы «Казанский музейный вестник» нәшер ителә, 125 еллык тарихы булган музей фәнни, экспозиция һәм мәдәни-белем бирү өлкәсендә гаҗәеп зур казанышларга ирешә.

Бөек Ватан сугышы елларында музейга хәрби трофейлар һәм башка экспонатлар бирелә. Сугыштан соңгы унъеллыкларда музей ТАССР яшәешен чагылдыра. Җирле сәнәгать предприятиеләре җитештергән продукция үрнәкләре, хезмәт батырлары һәм коллективларның хезмәт уңышлары экспозицияләрдә чагылдырыла. 1950 еллар урталарында Куйбышев ГЭСы төзелү сәбәбендә, су астында калачак зоналарда археологик тикшеренүләр үткәрелде. Шул экспедицияләр вакытында табылган тарихи әйберләр дә музей фондын тулыландырды.

Татарстанның Милли музее фондларында бүген 800 мең берәмлеккә якын материал саклана. Археологик фонд – иң зурысы. Биредә борынгы тарихыбыз һәм мәдәниятебез, палеолит, мезолит, борынгы тимер чоры, шулай ук Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларындагы экспонатларны күрергә була. Музейда хәтта Борынгы Греция һәм Мисыр әйберләре дә бар.


**Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.**

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# Тузан суыргыч кая киткән?

*Әгәр сатучы таләпләрне үтәү вакытын бозса.*

**Түбән Камада яшәүче Р., яңа тузан суыргыч сатып алгач, берникадәр вакыттан соң аның эшләгәндә бик нык кызуына игътибар иткән. Җиһаз гарантиядә булганлыктан, ул аны җитешсезлеген бетерү өчен кибеткә биргән һәм сатучыга тиешле таләпләр күрсәтелгән дәгъва тапшырган. Товарны ремонтка алу турында акт төзелгән. Ай ярым узганнан соң куллнучыга, куелган таләпләрне канәгатьләндерү өчен товарны кибеткә тапшырырга кирәклеген әйтеп, җавап хаты килгән. Тузан суыргыч кая киткән соң?**



Сатучыдан аңлаешлы җавап булмагач, куллнучы озак вакытлар товарны да, аның өчен түләнгән акчаны да ала алмаган. Нәтиҗәдә, ул Түбән Кама территориаль органының эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлегенә үз хокукларын яклауны сорап мөрәҗәгать иткән һәм анда үзенең язма хатын калдырган. Белгечләр тарафыннан юридик зат адресына закондарны аңлатып мөрәҗәгать әзерләнгән. 1992 елның 7 февралендә кабул ителгән «Куллнучыларның хокукларын яклау турында»гы РФ Законының 20 маддәсе нигезендә, әгәр товардагы җитешсезлекне бетерү вакыты якларның килешүе белән язма рәвештә билгеләнмәсә, әлеге кимчелекләр кичекмәстән, ягъни гадәттә кулланыла торган алымны исәпкә алып аларны төзәтү өчен кирәкле минималь вакыт эчендә бетерелергә тиеш.

Якларның килешүе белән язма рәвештә билгеләнә торган товарның кимчелекләрен бетерү вакыты кырык биш көннән дә артып китә алмый.

Нәтиҗәдә, вәзгыять куллнучы файдасына хәл ителгән: аңа тузан суыргыч акчасын кайтарып биргәннәр.

**Үз хокукларыгызны яклаудан курыкмагыз! Күп кенә сатучылар һәм башкаручылар, бөтен нечкәлекләрне белеп төзелгән дәгъваларны күргәч, эшне судка кадәр җиткермәскә тырыша һәм куллнучыларның таләпләрен канәгатьләндерә, чөнки эшнең судта каралуыннан һәм суд чыгымнарыннан (алар товар бәясеннән сизелерлек артып китә) куркалар.**

# Хезмәт күрсәтүдән баш тартсаң – штраф!

**«Минем ахирәтем – инвалид. Без еш аралашабыз. Һәм телефон аша гына түгел: өенә дә барам, кайчагында урамда йөрибез һәм кафега берәр чынаяк каһвә эчәргә керәбез. Әмма күптән түгел, яныбызга килеп, башка кафега баруыбызны сорадылар һәм моны даими клиентларның канәгать булмавы белән аңлаттылар. Законда җәмәгать урыннарыннан файдаланганда сәламәтлегендә кимчелекләр булган кешеләрнең хокукларын яклау каралганмы?**

**Ольга П.»**

Дөрестән дә, инвалидлар, өлкән яшьтәгеләр һәм социаль яктан якланмаган башка категориягә керүче гражданнарны транспорт инфраструктурасы, куллану, ял өлкәсе объектлары һәм хезмәтләреннән файдалану мөмкинлегеннән мәхрүм итү очраклары еш ишайды. Еш кына моның сәбәпчесе формаль, менталь, маркетинг, имидж һәм башка характерда була.

Шуны күздә тотып, РФ Президенты күрсәтмәсе белән, «РФ Административ хокук бозулар кодексының 14.8 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында»гы закон проекты әзерләнде. Анда әлеге маддәнә, закон нигезендә билгеләнгән очраклардан тыш, хокук бозуның яңа составы (куллнучыга аның эшчәнлеген чикләү, сәламәтлек торышы яки яше белән бәйле сәбәпләр буенча товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу, файдалану мөмкинлегеннән мәхрүм итү) белән тулыландырырга тәкъдим ителә.

**Роспотребнадзорга (аның территориаль органнарына) социаль яктан якланмаган категориягә керүче куллнучылардан мөрәҗәгатьләр килгән очракта, мондый гражданнарның хокукларын яклау һәм торгызу өчен тиешле барлык чаралар да күреләчәк.**

**Социаль яктан якланмаган категориягә керүче гражданнарга карата дискриминация күренешләре өчен закон нигезендә штраф санкцияләре кертү күздә тотыла. Вазифаи затлар өчен аның күләме – 15-30 мең, юридик затлар өчен 50-100 мең сум тәшкил итә.**

